Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

2018 нче елның 19 нчы ноябре 28№

“2018 елның 18 ноябрендә ТР Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлегендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында”

Федераль законның “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 70 статьясы, Федераль законның “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 22 статьясы нигезендә һәм 2018 елның 18 ноябрендә узган референдумда тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссиясенең 749 номерлы беркетмәсе (Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге башкарма комитеты) нигезендә авыл җирлеге Советы Карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә узган үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны узган, ә референдум нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2.” Сез яшәү урыны буенча Ташбилге авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган, ләкин 1 нче группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан,биш һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм 80 яшькә җиткән кешеләрдән тыш, 2019 елда һәр кешедән 600 сум үзара салым алыну һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган салым акчаларын түбәндәге эшләрне үтәү өчен куллану белән килешәсезме:

- урам яктырткычларын ремонтлау, лампаларны, яктырткычларны алмаштыру һәм урам яктыртуга тотылган электр энергиясе өчен түләү – 100 сум;
- авыл эчендәге юлларны карап тору һәм төзекләндерү – 265 сум;
- Ташбилге авыл җирлегенең үзәк паркы тирәсен тоту өчен җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру – 50 сум;
- су белән тәэмин итүнең урам системасын ремонтлау, су башнясын электр энергиясен куллану һәм суга лаборатор-инструменталь тикшеренүләр үткәрү өчен түләүгә-100 сум;
- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү, контейнерлар сатып алу (белгеч эше өчен түләү)-85сум” мәсьәләрен чишү буенча карар кабул ителгән дип танырга.

Референдумда катнашучылар исемлегендә тавыш бирү тәмамланган вакытта 329 кеше кертелгән;

тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны 304, бу 92,4 % тәшкил итә.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге референдумының тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга.

4. Әлеге карарны Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

Әлки муниципаль районы
Ташбилге авыл Советы Рәисе,
авыл җирлеге башлыгы

Әхмәдиев Р.Ф.